Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга
авыл җирлеге Советы

**КАРАР № LXVII-1**

Олы Елга авылы 2020 елның 4 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 октябрендәге “Җир салымы турында” IX-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 29 сентябрендәге “Россия Федерацисе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында” 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Уставына таянып,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге X-1 номерлы, 2015 елның 29 маендагы XXIII-1 номерлы, 2017 елның 22 августындагы XXXII-1 номерлы, 2019 елның 13 июнендәге LVIII-1 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән гайре)яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык

эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуальторак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре)җир кишәрлекләренә карата -0,3%”

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга  җирлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Казаклар авылы, Үзәк урамы, 9 йорт, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саескан Тавы авылы, Үзәк урамы, 16А йорт, Кама поселогы, Курорт-2 урамы, 23 йорт адреслары буенча урнашкан  махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл  җирлеге
Башлыгы

СОВЕТ
БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000235
ОЛЫ ЕЛГА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Ф.Ә Садриев